Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл жирлеге Мәләкәс авылы **ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

«21» октябрь, 2023 ел № 2

«Россия Федерациясендә жирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында жирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Тогаево авылы гражданнар жыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «2024 елда яшәү урыны буенча Мәләкәс авыл жирлеге Мәләкәс Мәләкәс авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1000 (бер мең) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 500(биш йөз) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә:

- янгын сүндерү машинасы өчен гараж төзү (төзелеш материаллары, жиһазлар сатып алу);

-торак пункт чикләрендә электр белән тәэмин итүне оештыру (яктырткычлар һәм электр жиһазлары сатып алу, монтажлау);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (кече архитектура формаларын урнаштыру һәм тоту);

- МКД территориясен төзекләндерү;

-зиратны саклау өчен материаллар сатып алу һәм урнаштыру.

2. Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл жирлеге Мәләкәс авылы гражданнар жыены нәтижәсен авыл жирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка житкерергә.

3. Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл жирлеге Мәләкәс авылы гражданнар жыены нәтижәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл жирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Гражданнар жыенында рәислек итүче,
Мәләкәс авыл жирлеге Башлыгы Ю.П.Васильев